**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17йорт, Актаныш ав.,423740

Тел. (85552) 3-44-22, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

_______________ ___________

**«Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең 2023 елга гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында»**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, «Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 30 декабрендәге 1096 номерлы «Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге гомуми белем бирү оешмаларын норматив финанслауны кертү турында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2023 елга «Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә һәм гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда тәрбияләнүчеләрне карап тотуга кушымтада бирелгән норматив чыгымнарны расларга.
2. «Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең финанс-бюджет палатасына, әлеге карарның 1 пункты белән расланган мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә, мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Л.Р. Сираевага мйөкләргә.

Җитәкче вазыйфасыш башкаручы Р.А.Ильясов

Расланган
«Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән
«___» ____________ 20___ №___

**«Актаныш муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә һәм гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда тәрбияләнүчеләрне карап тотуга норматив чыгымнар**

| Гомуми белем бирү оешмасының тибы һәм төре | Территориаль дислокация | Елына бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, сумнарда |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | авыл җирлеге | 105678 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | авыл җирлеге | 159325 |